КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 732

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 декабрь, 974 нче, 2016 ел, 14 гыйнвар, 12 нче, 2016 ел, 2 ноябрь, 807 нче, 2016 ел, 31 декабрь, 1094 нче, 2017 ел, 27 июнь, 441 нче, 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче, 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче; 2018 ел, 26 апрель, 296 нчы; 2018 ел, 26 ноябрь, 1053 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 69.2 статьясындагы 3 нче пункт нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең « Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик затларга күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия төп (тармак) исемлекләрен (классификаторларын) һәм гомумроссия төп (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең һәм күрсәтелүе һәм башкарылуы Россия Федерациясенең норматив хокук актлары белән күздә тотылган эшләрнең федераль исемлекләрен (классификаторларын) төзүгә, алып баруга һәм раслау турында» 2017 ел, 30 август, 1043 нче карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин